Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Апас муниципаль районы мәгариф бүлеге Иске Йомралы мәктәбе

# "Әниемә бүләк"

(СОЦИАЛЬ ПРОЕКТ)

Эшне башкардылар:
2нче класс укучылары
Җитәкчесе:
Миннегалиева.Р.Х

Иҗади проект-ул иҗади тәмамланган, балаларның яшь үзенчәлекләренә һәм мөмкинлекләренә туры килә торган, ирекле сайлау мөмкинлегенә ия булган, өлешчә мөстәкыйль эш төре.

Ул индивидуаль, коллектив һәм группада эшләнергә мөмкин.

Иҗади проект методы укыту сыйфатын үстерә ,балалар-ның һәм укытучының имиджын билгеләргә, танып-белү эшчәнлеген үстерүгә мөмкинлек бирә.Балаларның уку дәвамында кәефен күтәрә,белем алуга стимул булдыра.

Проблема һәрвакыт фикернең максатын билгели,ә максат фикер йөртүгә контрольлек итә.Иҗади проект методы исә нәкъ менә проблема өстендә эшләүгә нигезләнә.

Башлангыч мәктәптә иҗади проект астында нинди дә булса әйбер җитештерүне фикердән башлап эшне башкаруга кадәр үтәү процессы тора.

Хезмәт дәресләрендә эшләнә торган проектның максаты-интелектуаль, гомумихезмәт һүм махсус белемнәр һәм күнекмәләр системасын формалаштырудан гыйбарәт.

Иҗади проект эшчәнлеге белән идарә иткән укытучы түбәндәгеләрне исәпкә алырга тиеш.

1.Тикшереләсе мәсьәләләрнең ел дәвамында комплексы булуы.

2.Балаларның әзерлек дәрәҗәсе һәм физиологик мөмкинлекләре.

3.Экономик һәм материаль техник шартларның булуы.

4.Әлеге хезмәтнең җәмгыятькә яки шәхси яктан файдалы булуы.

5.Политехник юнәлеше.

6.Санитар-гигиена таләпләренә туры килүе.

7.Балаларның кызыксынуын исәпкә алу.

8.Милли- региональ компонентын исәпкә алу.

Иҗади проект өстендә эшләүнең 3 этабы бар.
1.Әзерләү-оештыру(1-2 дәрес)
2.Технологик этап.
3.Йомгаклау этабы.

Мин мондый тәртиптә эшләдем.

1.Проект төшенчәсен бирдем. Аның эчтәлеге ,планы белән таныштырдым. Тема билгеләдем.
2.Проблема билгеләдек.Ни өчен шундый мәсьәлә туды.Аны чишү өчен нәрсә эшләргә кирәк? Уйлау йолдызчыгы төзедек.

Нәрсә өчен кирәк?
Формасы
Декоратив бизәкләр
ӘЙБЕР
үзенчәлеге
Төсләр сайлау.
Материаллар

3.Иң шәп идеяларны сайлап алдык. Эшне башкаруның иң кулай ысулларын билгеләдек.Нинди җиһаз һәм материаль
кирәк булачагын билгеләдек. Куркынычсызлык кагыйдәлә-рен үтәүне искәрттек. Эш алымнарын тегү, кисүне искә төшердек.
4.Эшчәнлек ысулларын конкретлаштыру.Балалар әйбәт эшләделәр.Мин контроль ясадым.
5.Эшләгән эшкә йогак ясалды. Балалар бәя бирү өчен эти-әниләренә,дусларына күрсәттеләр.Сорауларга җавап бирделәр.

Биш көндә һәр көнне балалар иҗади проект көндәлегенә нәтиҗә яза бардылар.

# Проектның максаты һәм бурычлары:

***Максат: "Балаларны дөрес итеп инә тота белергә, апликация тегәргә.Өлге белән кисәргә өйрәтү***

Бурычлар:

- 1. Балаларның эшен күңелле , мавыктыргыч һәм файдалы итү.
- 2. Куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә.
- 3. Балаларда  матурлыкка мәхәббәт тәрбияләү.

# Проект идеясе

1.ПРОЕК ТӨШЕНЧӘСЕН БИРДЕМ.Аның эчтәлеге, планы белән таныштырдым.Тема билгеләдем.

2 Проблема билгеләдек.Ни өчен шундый мәсьәлә туды.Аны чишү өченнәрсә эшләргә кирәк? Уйлау йолдызчыгын төзедек.

3.Иң шәп идеяны сайлап алдык.Эшне башкаруның иң кулай ысулларын билгеләдек.Нинди җиһаз һәм тукыма кирәк булачагын билгеләдек.

4.Эшчәнлек ысулларын конкретлаштыру. Балалар әйбәт бик теләп ясадылар.Мин аларны күзәттем.

5.Эшләгән эшкә йомгак ясалды.Балалар теккән бияләйләрен иптәшләренә күрсәттеләр.Сорауларга җавап яздылар.

# Эш планы:

## 1. Хәзерлек этабы

- Мәсьәләне хәл итү, уйлау
- Сораштыру нәтиҗәләре;

Б алалар арасында сораштыру уздыру;

## 2. Төп этап

- Өлге  белән эшләү
- Сорауларга җавап бирү
- Тукыма белән эшләү

– Апликация тегү;

–Элгеч тагу

## 3.  Йомгаклау этабы

- Проектны яклау

Бияләйләр тегү өчен
Өлгеләр кирәк була
Җөйне җөйгә ялгау өчен
Зур тырышлык сорала



Тегү тегәм,тегү тегәм
Бармакны тишә-тишә
Эшем беткәнгә сөенәм
Бүләк итәм әнигә







Менә минем бияләйләр
Карагыз сез яхшылап
Кирәк булса сезгә дә
Тегәрмен мин бик теләп





Бияләйләр тегеп беткәч
Мактады укытучы
Укуларны сез бетергәч
Булырсыз чын тегүче















# Биремнәрне һәр укучы да төгәл үтәделәр


| Проекны яклау | Укучылар |
|---|---|
| Менә минем бияләйләр<br>Карагыз сез яхшылап<br>Кирәк булса сезгә дә<br>Тегәрмен мин бик теләп<br><br>Бияләйләр тегү өчен<br>Өлгеләр кирәк була<br>Җөйне җөйгә ялгау өчен<br>Зур тырышлык сорала<br><br>Бияләйләр тегеп беткәч<br>Мактады укытучы<br>Укуларны сез бетергәч<br>Булырсыз чын тегүче<br><br>Тырыша-тырыша тегү тегәм<br>Әниемә бүләккә<br>Шатланып алыр беләм<br>Бияләем кирәккә<br><br>Рәхмәт инде булыштыгыз<br>Бияләйләр тегәргә<br>Укытучым өйрәттең<br>Тукыманы җөйләргә<br><br>Тегү тегәм,тегү тегәм<br>Бармакны тишә-тишә<br>Эшем беткәнгә сөенәм<br>Бүләк итәм әнигә | Абдувалиева Д.Ш<br>Гимадиева. А.А.<br>Гиниятуллина И.Д<br>Сибгатуллина С.Р<br>Новоселова.Д А<br>Сираэев. М.Р.<br>Халиков.Р. А. |


# Укучылар көндәлеге.


Барлыгы
10 сум




Афәрин!
Җиңүегез белән кот-
лыйм.



# Көтелгән нәтиҗәләр

1. Балаларның шат күңелле, күтәренке рух белән эшне төгәлләделәр.
2. Эш вакытында туган кыенлыкларын көндәлекләренә яза бардылар..
3. Кулланылган тукыманың бәясен исәпләделәр.
4. Куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәделәр.
5. Нәтиҗә ясадылар. Тукыманы бер-берсенә беркетергә өйрәнделәр.Энә белән дөрес итеп тектеләр.
6. Теләгән  нәтиҗәгә ирештеләр.

# Рэхмэт.